# Үз тарихыңны белергә кирәк.

Шушы елның 12 октябрь санында “Ватаным Татарстан” газетасында Наил Шәрифуллинның “Юаш булсаң – басарлар, яки “Печелгәнлек” бәласе-2” дип аталган язмасы басылып чыкты. Мәкаләнең күпчелек өлеше милләтнең, татар кешесенең холкына, психологиясенә бәя бирүдән тора, монда дөреслеккә туры килгән урыннар да, арттырып җибәргән яки дөреслеккә туры килмәгән фикерләр дә бар. Халкыңның холкына бәя бирү – ул бик җаваплы нәрсә, үз анаң турында язу кебек. Төзәтү нияте белән, милләт тормышындагы тискәре якларны, татар тормышын тәнкыйтьләргә мөмкин, әмма аның күңел дөньясын гел кара һәм пычрак итеп күрсәтү милләтне аяк астына салып таптау булыр иде. Шуңа күрә мондый мәкаләләрне язганда, бик сак булырга кирәк, шәхси күзәтүләрдән чыгып кына татар кешесенә карата үтергеч гомумиләштерүләр ясарга ярамый, милләткә бәя бирү өчен дә бу тормышта яулап алган хакың булырга тиешле.

Газета битләрендә милли психология турында сөйләшүләр әле дәвам итәр, дип уйлыйм, әмма минем бу язмамда төп сүзем тарих турында булыр. Чөнки Наил Шәрифуллин татар тарихы алдына да шактый саллы һәм усал сораулар куя: “Кайда соң озын тарихыбызда азатлык байрагын гасырларга калырлык итеп күтәргән фидакарь көрәшчеләребез? – дип яза ул. – Милләт символы булырдай үз Шамилләребез, Боливарларыбыз?” Татарда Чыңгыз Айтматов кебек танылган язучылар, Нобель премиясе алган галимнәр, Сахаров, Лихачев кебек җәмәгать эшлеклеләре юклыгын санап китә дә, автор алга таба нәтиҗә чыгарып куя: “Ни кызганыч, андыйлар юк, булмады татарда.”

Безнең тарихыбызда милләт символы булырдай көрәшчеләребез бар, әмма аларны халык беләме-юкмы – анысы икенче мәсьәлә. Кулына каләм алып, милләткә бәя бирергә алынган кешеләр дә моны белмәгәч, безнең эшләребез, чыннан да, аяныч икән! Татарның Казан алынганнан бирле 455 еллык тарихы, гомумән, гел көрәштән тора – яшәү өчен көрәш, ирек өчен көрәш, татар булып калу өчен көрәш, дин өчен көрәш... Россия империясе татарның дәүләтен генә түгел, аны милләт буларак та юк итү максаты куя, ут һәм кылыч белән аның динен һәм телен юк итәргә ябыша. Дүрт гасырга сузылган мондый канлы эпопеянең әле бер генә дөнья тарихында да булганы юк, һәм шушы тарихның бу көнгә хәтле бөтен тулы фаҗигасе белән яктыртылганы да юк. Бер төрле йомшак милләт булса, бу кадәр изүгә, асуга-суюга, мәңгелек төрмәләрдә черетүгә, армияләрдә туп ите итеп файдалануга, радиацияле җирләрдә агулауга инде күптән юкка чыгып бетәр иде, көл булыр иде. Ә татар көлдән дә гөл булып килеп чыга, империя тарафыннан нинди зур каршылыклар булса да, егерме беренче гасырга ул үз теле һәм дине белән килеп керде, мәдәниятен һәм тарихын шушы көннәргә хәтле саклап китереп җиткерә алды! Мескен милләт моны эшли алмас иде!

Инде тарихи каһарманнар мәсьәләсенә килик. Алар татарда меңләгән. Казан өчен, татар җире өчен басып алучылар белән сугышып шәһит киткән һәр татар – ул милли каһарман, аларның урыннары җәннәттә булсын! Казан алынгач та, бу югалту белән килешмичә, татар дәүләтен яңадан торгызу өчен кяферләргә каршы корал тотып сугышкан **Гали Әкрам** гаскәре, Идел-Чулман буйларында, Арча, Биектау, Саба якларында халыкны изге сугышка күтәргән **Мамыш Бирде** яугирләре, уналтынчы гасыр азагына хәтле Себерне урыска бирмәс өчен сугышкан **Күчем** хан, Казан белән Әстерханны яңадан кайтару өчен Мәскәү белән сугышка чыкан Кырым ханнары, яу кырында ятып калган татар ирләре – алар милли каһарман түгелмени? Татар халкы бер кайчан да үзенең коллыгы белән килешмәгән һәм гасырлар дәвамында басып алучыларга каршы көрәшкә күтәрелгән. Урыс тарихында чын исемен яшереп, “Крестьян сугышлары” дип өйрәнелгән восстаниеләр – алар барысы да диярлек татарларның урыс патшасына, Рәсәй империясенә каршы алып барган азатлык

сугышлары ул. Унҗиденче гасыр башында Казанны урыслар кулыннан тартып алу өчен бөтен Мишәр Йортын күтәргән татар батыры **Җан Гали**, 1670 елда, 15 мең кешелек татар гаскәре туплап, Казанны алырга килгән касыйм татары **Хәсән Карачурин**, 1680 елларда милләтне җиһадка күтәргән мулла **Сәет Садур, Солтан Морат** – алар милли каһарман түгелмени?

Әмма Казан алынганнан соң татар халкы өчен иң фаҗигале чор – унсигезенче гасыр була. Чөнки монда дәүләтнең генә түгел, милләтнең язмышы хәл ителә, татар халкы яшәү белән үлем арасында кала. Халыкны талау, кул-аякларыннан чылбыр белән монастырьларга асып куеп, көчләп чукындырулар, җәза отрядлары һәм патша гаскәрләре белән кырып чыгулар, чукынмаган өчен салым түләтүләр, яңадан ислам диненә кайткан өчен яндырып үтерүләр, кол итеп тимер рудникларында, шахталарда эшләтүләр, мәңгелеккҗә солдатка алып, туп-туры үлемгә җибәрүләр – болар барысы да татар халкы күргән җәбер-газаплар бит! Һәм шушы шартларда да татар ирләре халыкны басып алучыларга каршы яуга күтәрә ала, унсигезенче гасыр тоташы белән татар күтәрелешләреннән тора! Гасыр башында татар яулары белән **Сәгыйть Җәгъфәр** һәм **Теләкәй** батырлар җитәкчелек итә, 1705-1711 елларда милли азатлык көрәше башына **Теләкәй улы Күчем** баса, 1735-1740 елларда татар явы белән **Күчем улы Акай** һәм **Акай улы Габдулла** җитәкчелек итәләр. Күрәсез, татарлар бөтен нәселләре, авыллары, ил-җирләре белән басып алучыларга каршы сугышалар. Патша хөкүмәте бу татар күтәрелешләрен рәхимсез рәвештә бастыра, башлап йөрүче татар яугирләрен дүрткз өздереп, очлы казыкларга утыртып, кабыргаларыннан асып, башларын чабып, җәзалап үтерә, тел-борыннарын кисеп алып, маңгайларына  “Вор” дигән утлы тамга баса. 1740 елның 25 августында, Ырынбур далаларында, урыс генераллары күзәтүе астында, 6 мең татарны әнә шулай җәзалыйлар, болар барысы да тарихта язып калдырылган.

Россия империясе татарларга каршы вәхшилегендә шул дәрәҗәгә барып җитә ки, көчләп чукындырылганнан соң яңадан ислам диненә  кайткан өчен татарларны патша Указы белән яндырып үтерә башлыйлар. Без тарихчы дип йөргән урыс генералы Василий Татищев, 1738 елның 20 июнендә, Екатеринбург шәһәрендә, чукындырганнан соһң яңадан ислам диненә кайткан татар кешесе Тойгелде Җуләковны тереләй утта яндырып үтерә. Үтерер алдыннан аңа патшабикә Анна Ионовнаның фәрманын кычкырып укыйлар, анда түбәндәге юллар була:

“По Указу Ея императорского Величества самодержицы Всероссийского и по определению его превосходительства Тайного Советника Василия Никитича Татищева, велено тебя, татарина Тойгельду, за то, что ты, крестясь в веру греческого исповедения, приняли паки махометанский закон, и не только что в богомерское преступление впал, но яко пес на свои блевотины возвратился, и клятвенное свое обещание, данное при крещении презрел, чем Богу и закону его праведному учинил великое противление и ругательство, - на страх другим таковым, кои из махометанского приведены в христианскую веру, при собрании всех крещенных татар велено казнить смертию – сжечь!” (Анисимов Е.В. Дыба и кнут. Политический сыск и русское общество в XVIII веке. – М., 1999. С. 541-542.)

1736-1737 елларда гына да Идел-Урал арасында 696 татар авылы яндырыла, 17 меңнән артык татар җәзалап үтерелә, 4 мең татар мәңгелек сөргенгә сөрелә, 10 мең татар хатын-кызы һәм балалары урысларга коллыкка бирелә. 1740 елның август-сентябрь айларында урыс генералы Соймонов әмере буенча Себер-Нугай юлларында тагы 537 татар авылы яндырыла, Уфа өязендә 725 татар авылы юк ителә, 3665 татар ире яу кырында үтерелә, 404 татар ире соңыннан җәзалап үтерелә, 802 кеше мәңгелек сөргенгә сөрелә, 3026 татар хатын-кызы һәм балалары урысларга коллыкка бирелә. Болар барысы да тарихка теркәлеп калган. Мондый җан өшеткеч мисалларны меңләгән

китереп булыр иде, алар архив документларында саклана, бу хакта хәзер татар тарихчылары да яза. Әмма милләт болар турында белми, болар турында әдәби әсәрләр дә юк дәрәҗәсендә, кинофильмнар да, телевизион тапшырулар да юк. Шуңа күрә хәтта милләт темасына язучылар да тарихның бу чорын әйләнеп үтәргә тырышалар, гаепне гел татарның үзеннән эзләп, татар халкына каршы гасырларга сузылган канлы геноцидны күрмәмешкә салыналар.

Менә шушы чорда милләтне чукындырудан һәм юкка чыгудан саклап калу өчен Аллаһы Тәгалә татар халкына Батыршаны бирә. Баһадиршаһ – Батырша – Габдулла Гали 1755 елны Идел-Уралда, Себер-Нугай юлында яшәүче мөселманнарны, беренче чиратта, татарларны, башкорт һәм казахларны урыс басып алучыларына каршы изге сугышка чакырып, мөрәҗәгать белән чыга. Бу вакытта инде көчләп чукындырулар, мәчет-мәдрәсәләрне юк итү, төрки-татар халкын бер хокуксыз кол итеп, хайван дәрәҗәсендә тоту үзенең иң биек ноктасына менеп җиткән була. Җитмәсә, мөселман-татарлар чукынган татарлар өчен дә налог түли, солдат бирә, авылда бер чукынган татар булса, бөтен мөселман-татарлар башка җиргә күчеп китәргә тиеш булалар. Алга таба да шулай дәвам итсә, татар халкы бетәчәк була.

Менә шушы куркынычны бөтен йөрәге, акылы белән сизгән, илдәге вәзгыятьне һәм сәясәтне бик яхшы белгән Батырша татар халкын басып алучы кяферләргә каршы изге сугышка күтәрелергә чакыра: “Әй, дөрес игътикадлы, пакь динле мөэминнәр, катланыгыз! Берләшегез! Берләшегез! – дип яза ул өндәмәсендә. – Газилек атларыгызны һәм коралларыгызны әзерләгез! Ук, кылыч, сөңге вә һәр ни кирәк, хәлегезгәчә хәзерләнегез! Аллаһы Тәгаләнең әмеренә итагать итеп һәм буйсынып, Аңа тәвәккәл итеп, пђәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһу галәйһиссәламне шәфиг китереп, ул кяфер урысны чабаек вә аларны җиребездән куып чыгарыйк! Ил-йортыбызда мәсҗидләр вә мәдрәсәләр бина кылыйк! Вә динебезне, ислам динен куәтләндерергә һиммәт кылыйк!” (Батырша – выдающийся идеолог и вдохновитель восстания башкир. 1755-1756 гг. – Уфа, 2000 г.)

Бер караганда, империянең йөзәр меңлек регуляр гаскәренә, утлы коралына һәм чуен тупларына каршы кылыч тотып чыккан Батырша хәзрәт һәм аңа ияргән татарлар сәер күренергә дә мөмкин, чөнки көчләр тигез түгел, көрәшне ничек бетәсен чамаларга була. Коръәнхафиз дәрәҗәсендә гыйлем, ахунлыкка тәкъдим ителгән ил агасы Батырша хәзрәт моны яхшы аңласа да, халыкны шушы тигезсез көрәшкә, кяферләргә каршы изге сугышка чакыра һәм оештыра башлый. Чөнки ул, дин әһеле буларак, мөселманнарның кяфер кул астында газап күрүе белән ризалаша алмый, чөнки Коръән дә мондый вакытта я – җиһад, я – һиҗрәт, ди. Ә инде бөтен милләт белән каядыр күчеп китү мөмкинлеге булмаганда, динеңне, телеңне һәм үзеңне саклап, сугышырга гына кала. Батырша хәзрәт моның дин һәм ил өчен соңгы сугыш булуын яхшы аңлый, шуңа күрә, үлемнән курыкмыйча, кулына кылыч алып империя аждаһасына каршы ташлана...

Әлбәттә, Батырша хәзрәт һәм аның тарафдарлары җиңелә, чөнки кол ителгән һәм изелгән милләт оешып китә алмый, чөнки милләтнең үз арасыннан да инде урысларга сатылучылар өлгереп җитә, чөнки бер төркем мөселман-татарларга каршы Рәсәйнең йөз меңлек регуляр гаскәре сугышка чыга. 1756 елның 8 августында Батырша хәзрәтне тотып алып, аяк-кулларын богаулап, башта Уфа, аннан Ырынбур төрмәсенә озаталар, аннан исә ул көчле сак астында Мәскәү аша Петербургка җибәрелә. 1757 елның 24 декабрендә Батыршага хөкем карары чыгарыла, аны патша хакимиятенә каршы коткы таратуда, татар халкын урысларга каршы сугышка чакыруда гаеплиләр. Бу эштә төп дәлил итеп аның мөселманнарга язган өндәмәсе алына, шулай ук ул чорда төбәктә кабынып киткән баш күтәрүләрне дә Батырша исеме белән бәйлиләр. Ул дәүләт өчен куркыныч кеше, дип табыла һәм мәңгегә төрмәгә ябырга хөкем ителә. Хөкем карарында шулай ук Батыршаның телен һәм борынын кисеп алу, камчы белән суктыру

да күрсәтелгән була. Ике көннән бу карар тормышка ашырыла – Батыршаның тимер кыскыч белән телен һәм борын яфракларын өзеп алалар, үтергәнче камчы белән яралар. Гадәттә, камчы белән берничә тапкыр суктырудан кеше үлә, ә Батыршаны, төрмә белешмәләреннән күренгәнчә, 40-50 тапкыр суктыралар. Ул исән кала... Канга баткан татар мулласын, көчле сак астында, кыш уртасында Шлиссельбург төрмәсенә китереп ташлыйлар. Биредә, ялгыз камерада, ул биш елга якын утыра, һәм 1762 елның 24 июлендә, нindидер могҗиза белән кулына балта алып, үзенә ташланган дүрт урыс солдатын бәреп үтереп, аяк-куллары богаулы килеш иреккә кача... һәм төрмә ишеге төбендә йөрәге ярылып үлә...

Батырша хәзрәтнең хатыны Зөлхәбирәне һәм кызлары Зөләйха белән Салиханы, чукындырып, монастырьга ябалар, алар шунда үлә. Уллары Таҗетдин, Уфа төрмәсеннән Мәскәү төрмәсенә конвой белән озатканда, юлда өшеп үлә. Батырша хәзрәтнең бөтен нәселе милләт азатлыгы өчен корбан була. Әмма шушы канкойгыч хәлләрдән соң патша Россиясе татарларга карата ташламаларга барырга мәҗбүр була – көчләп чукындырулар туктатыла, чукынмаган мөселман-татарларны туган авылларыннан сөрүләр туктатыла, мөселман-татарларның чукынган татарлар өчен армиягә барулары һәм налог түләүләре бетерелә. Шулай ук патшабикә Елизавета Петровна әмере белән, Идел-Урал арасында мәчетләр салырга рөхсәт ителә, көчләп чукындырулары белән татарларның бәгыренә төшкән Казан архиерее Лука Канашевич һәм Тубыл митрополиты Сильвестр Гловацкий, мөселманнар таләбе белән, башка урынга күчерелә. Шулай итеп, Батырша хәзрәт үз гомерен корбан итеп, татар халкын, Идел-Уралны һәм хәтта кыргыз-казахны чукындырудан саклап кала, милләтнең күңеленә өмет чаткылары салып калдыра. **Шуңа күрә без Батырша хәзрәтне, азатлык байрагын югары тоткан милли каһарман, дип әйтә алабыз**.

Унсигезенче гасыр азагында кабынып киткән Пугач явы да, нигездә, 200 мең кешелек татар гаскәреннән тора һәм алар арасында Батырша хәзрәт шәкертләре дә була. Яу башына урысның үзен бастырып булса да, аның ялган патша икәнлеген яхшы белсәләр дә, татарлар Рәсәй империясенә каршы сугышка күтәреләләр һәм иң беренче эш итеп, Казанны алырга юнәләләр. Күпме асыл затлар, чын мәгънәсендә, каһарман татар ирләре була алар арасында! Алар Ырынбур, Богырыслан, Бозаулык, Уфа, Троицк, Магнитка, Җаек, Чиләбе, Пермь, Ижау, Воткинск, Әгерҗе, Зәй, Алабуга, Мамадыш, Арча, Цивильск, Курмыш, Алатырь, Саранск, Пенза, Петровск, Саратов, Камышлы, Царицын һәм Казан өчен сугышлар алып баралар һәм аларның күпчелеген, шул исәптән Казанны да патша армиясе кулыннан тартып алалар. Казан бер көн Пугачев явы татарлары кулында булып тора, әмма патша гаскәре аңа ут төртә һәм Казан 12 җирдән дөрләп яна башлый. Яу белән килгән татарлар һәм урыс регуляр гаскәре өч көн, өч төн Казан янына чыгып сугышырга мәҗбүр булалар. Әмма милләт өчен бу хәлиткеч сугышта татарлар җиңелә, биш мең кеше әсир итеп алына, соңыннан Пугачевның үзен дә тотып алып, Мәскәү уртасында җәзалап үтерәләр. Пугачев белән бергә Казан өчен, ирек өчен яуга күтәрелгән татарларның да күбесен шундый кара язмыш көтә. Менә алар, татар тарихына алтын хәрефләр белән язылырга тиешле татар каһарманнары - **Мәсәгуть Гомәров, Бәхтияр Канкаев, Канзафар Усаев, Габделҗәлил Сөләйманов, Муса Галиев, Габделкәрим Рахманкулов, Аит Уразмәтов, Габдрәшит Аитов** һәм азатлык өчен көрәшеп, Рәсәй төрмәләрендә, каторгаларда җан биргән меңләгән татар ирләре... Аларның урыннары җәннәттә булсын!

Халык алар турында белмәскә дә мөмкин, әмма милли зыялылар боларны белергә һәм милләткә җиткерергә тиеш. Җәмит Рәхимовның 1992 елда басылып чыккан “Батырша” романы, галим Фәйзелхак Ислаевның соңгы елларда дөнья күргән фәнни хезмәтләре, без фәкыйрегезнең 2005 елда басылып чыккан “Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше” һәм 2006 елда дөнья күргән “Баһадиршаһ” әдәби-документаль

романы, 2004 елда “Мәгариф” нәшриятында басылган “Туфаннан таралган татарлар” китабы, әле быел гына дөнья күргән “Күчем хан” романы каһарман татарлар турында күп мәгълүмат бирә алыр иде. Ә инде мәкалә авторы Наил Шәрифуллин идеаллаштырган җәмәгать эшлеклеләре Сахаров һәм Лихачевларга килгәндә, монда әле уйланырга урын бар. Билгеле булганча, Сахаров водород бомбасын уйлап табучы галим, ягъни, гыйфритне шешәдән чыгаручыларның берсе. Бу үлем коралының кешелеккә нинди куркыныч тудыруын аңлап алып, Сахаровның үз “иҗат җимешенә” каршы эшли башлавы табигый хәл. Монда гөнаһ һәм савап тәлинкәләре тигез, батырлыкка бик тартмый. Ә инде академик Лихачевның күпчелек хезмәтләре бөек рус шовинизмы белән сугарылган, ул башка халыкларны, шул исәптән, татарларны да исәпкә алмады, урыс өчен генә тырышты. Шулай булгач, ул безнең өчен нинди идеал булсын? Олҗас Сөләйманов белән Чыңгыз Айтматов та, урысча язмасалар, үз милләтләрендә әллә ни танылу тапмаслар иде. Ә инде кавказ халкының милли каһарманы имам Шамиленә килгәндә, урысларга әсирлеккә төшкәч, ул төрмәдән Рәсәй белән мәңге дус-тату яшәргә чакырып, хатлар яза, шуның өчен аны ireккә чыгаралар. Минем өчен имам Шамилгә караганда, кулына кылыч тотып, сукырайган хәлдә 20 ел буе Себерне урысларга бирмәс өчен көрәшкән һәм яу кырында шәһит киткән татар ире Күчем хан кадерлерәк.

Татар милләтендә талантлар күп, көрәшчеләр дә бар, әмма аларны үз вакытында күреп, бәя бирүче бәйсез дәүләтебез юк безнең. Минем өчен **Габдрәшит Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Муса Бигиев, Ризатдин Фәхретдинов, Һади Атласи** бәя биреп бетергесез зур шәхесләр, талант ияләре, галимнәр, көрәшчеләр, мин аларны бер милләтнең бер бөегенә дә алыштырмас идем. Узган гасырның 90нчы еллары башында милләтнең азатлыгы өчен мәйданнарга чыккан һәр татар – миннем өчен милли каһарман. Гомумән, бу елларда татар халкы үзе милли каһарманга әйләнде, үзенең азатлыгы өчен көрәшкә күтәрелде. Без, татарлар, бөтен дөньяны атом бомбалары белән куркытып торган Рәсәй аждаһасының күзенә карап, үзебезнең азатлыкка хаклы булуыбызны әйтә алдык, бу батырлык түгелмени? Россиядә шушы сүзне әйтә алырлык без бердәнбер милләт идек, чөнки чеченнар бездән соң гына күтәрелде. Без, үзебезнең азатлыкка хаклы булуыбызны раслап, Декларацияләр кабул иттек, референдумнар үткәрдек һәм җиңдек, республикага куркыныч килә башлагач, ачлык мәйданнарына чыгып яттык, йөз меңләгән татарны урамнарга чыгардык һәм Татарстанны, татар халкын йотарга әзер булган Рәсәйне чигенергә мәҗбүр иттек. Без хәзер дә үзебезнең бәйсез дәүләт төзәргә хаклы икәнлегебезне империянең күзенә карап әйткән һәм шуның өчен көрәшкән Рәсәйдәге бердәнбер милләт булып кала бирәбез. Үзенең мәкере, явызлыгы, үлем кораллары белән дөньяны тетрәтеп торган Рәсәйгә каршы татарның азатлык явына күтәрелүе – ул каһарманлык түгелмени?! Юк, татар халкы, мәкалә авторы язганча, аумакай һәм сатлыклардан гына тормый, аның ирек өчен утка керерлек ул-кызлары да бар, шөкер! Мең шөкер! Һәм милләтне алар алга алып барачак, алар коткарачак.

**Фәүзия Бәйрәмова,**

язучы*, тарих фәннәре кандидаты, “Иттифак” татар милли бәйсезлек партиясе рәисе, Бөтендљнья татар конгрессының башкарма комитеты әгъзасы.*

2007 ел, 23 октябрь.